СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 29 от 03.11.2020
на № __от ________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Югары Симет авыл җирлегенен
Генераль планын раслау турында

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә гамәлдәге законнарны үтәү максатларында, Россия Федераңиясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принңиплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниңипаль районы Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниңипаль районы Советының 2006 елның 21 ноябрендәге 94 номерлы карары белән расланган Саба муниңипаль районында ачык тыңлаулар турындагы Нигезләмә нигезендә, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре муниңипаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булып торуын һәм авыл җирлекләре территорияләрендә муниңипаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бәяләмәсенең булуын исәпкә алып, уздырылган ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча, Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниңипаль районы Югары Симет авыл җирлегенең Генераль планын расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниңипаль районы Югары Симет авыл җирлегенең Генераль планын раслау турында” 2017 елның 12 апрелендәге 108 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниңипаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниңипаль
районы Башлыгы

Р. Н. Минниханов